ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МҮЛМӘ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422731, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Мүлмә авылы, Үзәк ур., 46а

СОВЕТ МУЛЬМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422731, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Мульма , ул.Центральная, 46а

тел./факс 8(84365) 70-2-03, e-mail: Mulm.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

22 июль 2019 ел № 159

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге тарафыннан шәһәр төзелеше өлкәсендә җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен кабул итү турында**

Биектау муниципаль районы Советының “Биектау муниципаль районы башкарма комитеты һәм Биектау муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләре башкарма комитетлары арасында җирлекләрнең генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен эшләү һәм раслау буенча вәкаләтләрне тапшыру турында килешүләрне раслау турында”, 2019 елның 30 маендагы 300 номерлы карарын караганнан соң, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, “Мүлмә авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы белән эш йөртеп, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Советы,

КАРАР ИТТЕ:

1. “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 ст. 3 һәм 4 бүлекләре нигезендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген тормышка ашыру өлешендә вәкаләтләрнең бер өлешен кабул итәргә.

Кабул ителә торган вәкаләтләрнең тормышка ашыру предметы булып торалар:

- җирлекнең генераль планын раслау;
- җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау;
- җирлекләрнең шәһәр төзелеше проектлавының җирле нормативларын раслау.

2. Мүлмә авыл җирлеге Башкарма комитетына Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты белән шәһәр төзелеше эшчәнлеген тормышка ашыру буенча килешү төзергә.

3. Әлеге карарны Мүлмә авыл җирлеге Башлыгына имза куюга тапшырырга.

4. Әлеге карарны Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы һәм Татарстан Республикасы

хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үз көченә керә.

Совет рәисе урынбасары
Мүлмә авыл җирлеге башлыгы урынбасары Р.Р. Гарафиев